ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.01.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 112**

Территориянеӊ кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнеӊ административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Территориянеӊ кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнеӊ административ регламентын кушымтада каралганча расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Территориянеӊ кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнеӊ административ регламентын раслау турында»гы 2021 елның 28 июлендәге 1762 номерлы карары үз көчендә югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында , Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 21 гыйнварындагы
112 номерлы карарына
кушымта

**Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү, Хезмәт күрсәү).

2. Хезмәт күрсәтүне алучылар: физик затлар (шул исәптән индивидуаль эшкуарлар) һәм юридик затлар (алга таба -мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләр мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләр тапшырылган затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) тәкъдим итә ала.

3. Хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүчегә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә бирелергә тиеш (алга таба - Бердәм портал).

## II. Хезмәт күрсәтү стандарты

### Хезмәт күрсәтү атамасы

4. Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау.

### Хезмәт күрсәтүче органның атамасы

5. Хезмәтне «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе күрсәтә.

### Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Мөрәҗәгать итүче «Территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау» ны сорап мөрәҗәгать иткәндә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып:

1) Территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар (5, 6 нчы кушымта);

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (7 нче кушымта).

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча, хезмәт күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрелә (8 нче кушымта).

7. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Палатаның вазыйфаи затының көчәйтелгән

квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Бердәм портал, Республика порталының шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе күп функцияле үзәктә Палата тарафыннан юлланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә, күп функцияле үзәк мөһере һәм күп функцияле үзәк хезмәткәре имзасы белән расланган, кәгазьдә бастырылган рәвештә алынырга мөмкин.

9. Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә яисә электрон документның нөсхәсен кәгазь саклагычта Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

## Хезмәт күрсәтү срогы

10. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы – 10 эш көне.

Төзелә торган җир кишәрлегенең территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарда булуы турында мәгълүмат булганда һәм тикшерү үткәрү өчен җир кишәрлегенә бару кирәклеге очрагында муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты 22 эш көненнән дә артмый.

11. Әгәр вәкаләтле органга җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең территориянең кадастр планында урнашу схемасын раслау турында гариза кергән көнгә мондый орган каравында төзелүе әлеге гаризага кушымтада бирелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасында каралган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза булса, моңа кадәр башка зат тарафыннан бирелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы һәм әлеге схемаларда каралган җир кишәрлекләренең урнашу урыны өлешчә яисә тулысынча туры килсә, вәкаләтле орган территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау турында соңрак бирелгән гаризаны карау срогын туктатып тору турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.Җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау турында соңрак бирелгән гаризаны территориянең кадастр планында карау срогы җир кишәрлегенең урнашуының элек җибәрелгән яисә тапшырылган схемасын раслау турында карар кабул ителгәнгә кадәр яисә күрсәтелгән схеманы раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнгә кадәр туктатып торыла

12. Хезмәтне күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән соң икенче көннән исәпләнә башлый

13. Электрон документ формасындагы Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү, Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны Палатада һәм күпфункцияле үзәктә бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

## Хезмәт күрсәтү өчен гаризаны һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм Хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

14. Хезмәтне күрсәтү өчен гаризаларны һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карарны Палата түбәндәге нигезләр булганда кабул итә:

1) Регламентның 3 нче кушымтасында билгеләнгән документларны тапшырмау;

2) ведомствоара мәгълүмати бәйләнеш кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турында белешмәләр расланмау, мөрәҗәгать итүче исеменнән гариза (рәсми мөрәҗәгать) моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;

3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

4) дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр, килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлеген аңларга мөмкинлек бирми торган җитди зарарланулар булган документларны, үз көчен югалткан документларны тапшыру;

5) Регламент нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүне алучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри юлларны корректлы тутырмау, электрон формада һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу;

7) электрон рәвештәге гаризага (рәсми мөрәҗәгатькә) һәм башка документларга электрон имза гамәлдәге законнарны бозып куелган;

8) электрон документлар тапшыру форматларына куелган таләпләргә туры килми һәм (яисә) укылмыйлар.

15. Әгәр гариза Палатага кергән көнгә Палата каравында башка зат тарафыннан элегрәк тәкъдим ителгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы һәм әлеге схемаларда төзелүе каралган җир кишәрлекләренең урнашу урыны өлешчә яисә тулысынча туры килгән булса, Хезмәт күрсәтү туктатып торыла.

16. Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карарны Палата түбәндәге нигезләр буенча кабул итә:

1) Җир кишәрлегенең урнашу схемасы аның формасына, форматына яисә аны әзерләүгә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясындагы 12 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

2) барлыкка килү схемасында каралган җир кишәрлегенең урнашу урыны җир кишәрлегенең гамәлдә булу срогы чыкмаган җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында элек кабул ителгән карар нигезендә төзелә торган җир кишәрлегенең урнашу урыны белән тулы яисә өлешчә туры килүе;

3) төзелә торган җир кишәрлекләренә карата РФ Җир кодексының 11.9 статьясы таләпләрен бозып, җир кишәрлегенең урнашу схемасын эшләү;

4) җир кишәрлеге урнашу схемасының территорияне планлаштыруның расланган проектына, җир төзелеше документларына, аеруча саклана торган табигый территория турындагы нигезләмәгә туры килмәве;

5) территорияне ызанлау проектында расланган территория чикләрендә, җир кишәрлегенең урнаштыру схемасында ясау күздә тотылган җир кишәрлегенең урнашуы, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш;

6) территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә генә барлыкка килергә рөхсәт ителә торган җир кишәрлегенең урнашу схемасын эшләү;

7) җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы хәбәрнамәсе;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче инициативасы белән кире алу.

17. Хезмәт күрсәтү өчен гаризаны һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре, мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, Хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

### Хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

18. Хезмәт күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

### Хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать иткәндә һәм Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

19. Хезмәт күрсәтүгә гариза биргәндә көтү вакыты - 15 минуттан артык түгел.

20. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең Хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы.

21. Күп функцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза тапшырылган көнне күп функцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры һәм гариза бирү көне күрсәтелгән раслама бирелә.

22.Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номерын һәм гариза бирү датасын күрсәтеп, гариза җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәрнамә ала.

23. Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаны ике нөсхәдә тапшырган көнне, Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документлар күрсәтелгән бер нөсхәсе кире кайтарыла.

Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр

24. Хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

25. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә Хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатыннан түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) Хезмәт күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (бинага/биналардан керү/чыгу һәм алар чикләрендә уңайлы хәрәкәт итү);

2) Хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат саклагычларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-ноктала шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

7) сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау Министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге «Озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документ булган очракта, юл күрсәтүче этне кертергә рөхсәт итү.

26. Хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга инвалидларның керү мөмкинлеген һәм Регламентның 24 пунктының 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән

хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

27. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр турында мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында, КФҮ, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре

28. Хезмәт күрсәтүнең файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре түбәндәгеләр:

документларны кабул итү алып барыла һәм тапшыра торган бинаның җәмәгать транспорты йөргән урыннарга якын урнашуы;

кирәкле белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуда комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.

29. Хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срогын үтәү;

2) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу срокларын үтәү;

3) Палата хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) Хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән аралашуы гариза белән барлык кирәкле документларны биргәндә бер тапкыр башкарыла;

4.2) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә электрон документның кәгазь нөсхәсе рәвешендә алу кирәк булган очракта – бер тапкыр.

Хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән бер тапкыр аралашу озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм портал, Республика порталы, терминал җайланмаларын кулланып бәяләргә хокуклы.

30. Хезмәт күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яки Республика порталында шәхси кабинетында, күп функцияле үзәктә алырга мөмкин.

31. Хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә, яшәү урынына яки фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

32. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне комплекслы рәсми мөрәҗәгать составында алырга хокуклы.

33. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре турында мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында, күпфункцияле үзәктә, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Хезмәт күрсәтүгә карата башка таләпләр

34. Хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган Хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) Хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) Хезмәт күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларның үтәлеше барышы һәм статусы турында белешмәләр алырга;

г) Хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә бәяләргә;

д) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм башкарылган (башкарылмаган) гамәлләргә карата судка кадәр (судтан тыш) Бердәм портал, Республика порталы, шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша Палатаның, шулай ук андагы вазифаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм башкарылган (башкарылмаган) гамәлләренә карата шикаять бирергә.

35. Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, теләсә нинди башка формада гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

36. КФҮтә кабул итү өчен мөрәҗәгать итүчеләрне теркәү (алга таба - язылу) Бердәм, Республика порталы, КФҮ контакт телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә кайсы буш датага һәм вакытка кабул итү өчен язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге көн башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Бердәм портал, Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратып алына торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк,, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләге буенча);

кабул итү буенча теләгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу вакытында хәбәр ителгән белешмәләр шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгать итүче тапшырган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүчегә талон-расламаны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән кабул итү вакытыннан соң 15 минут үткәч килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында аңа мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылудан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы аралыгын исәпләп

чыгару өчен кирәк булган белешмәләр бирүдән тыш, башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

37. Җир кишәрлеген электрон документ рәвешендә урнаштыру схемасын әзерләү «Пространство белешмәләренең милли системасы» бердәм цифрлы платформасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

38. Регламентның 3 нче кушымтасындагы таблицада Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, алар түбәндәгечә бүленә:

а) Хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар ;

б) Хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга хокуклы документлар.

39. Хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар формалары турында белешмәләр әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

Административ процедуралар исемлеге

40. Хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) Хезмәтне күрсәтү өчен гариза һәм документларны кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш;

3) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

Ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш

41. Хезмәт күрсәтүне алу өчен «Ведомствоара электрон үзара бәйләнешнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрергә кирәк:

1) «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (күчемсез мөлкәт объектының төп характеристикалары һәм теркәлгән хокуклары турында белешмәләр)дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра;

2) «Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Федераль салым хезмәте»нә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте»соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.Рәсми мөрәҗәгать юридик зат хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

3) «Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Федераль салым хезмәте»нә

җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.Рәсми мөрәҗәгатьиндивидуаль эшкуар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла.

42. Хезмәт күрсәтүне алу өчен башка сервислар аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрү кирәк:

1) «Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестры» сервисы я «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә, мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, 1 эш көненнән артык булмаган вакытта гамәлгә ашырыла;

2) «Ышанычнамәне бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 2 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

3) «Адресация объектына бирелгән адрес турында белешмәләр»дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль мәгълүмати адреслы система» сервисы ярдәмендә 2 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

4) «Сораштырыла торган җир кишәрлегендә корылмалар барлыгы турында белешмәләр» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать«Электрон хуҗалык кенәгәсе» сервисы ярдәмендә 2 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

5) «Җир кишәрлеге бирү өчен чикләүләр булу яисә булмау турында белешмә (шул исәптән территориаль зона, кызыл линияләр чикләре турында, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары булу)» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

6) «Су объектларының чикләре турында белешмәләр» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгыннан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

7) «Урман кишәрлекләре чикләре турында белешмәләр» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгыннан5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

## IV. Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

43. Техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүче Регламентта билгеләнгән хезмәтләр күрсәтүгә үзенең рәсми мөрәҗәгать статусы үзгәрү турында (документлар кабул итү турында; документлар комплектын карау турында; хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтү турында), шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнары һәм гамәлләре турында санап үтелгән түбәндәге ысулларның берсе буенча хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
– Бердәм портал ярдәмендә;
– Республика порталы ярдәмендә;
– башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

Регламентка
1 нче кушымта

**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТЫЛМАЛАР ИСЕМЛЕГЕ**

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3. Федераль дәүләт мәгълүмат системасы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең федераль реестры» (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. Зеленодольск муниципаль районы порталы» мәгълүмат системасы (https://zelenodolsk.tatarstan.ru/) – Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты;
5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты – Башкарма комитет;
6. Зеленодольск муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МУ – Палата;
7. Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ.

Регламентка
2 нче кушымта

**Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары**

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билге атамасы | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билге идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслау турында карар | Физик зат | 1А |
| 2 | | Юридик зат | 2А |
| 3 | | Индивидуаль эшкуар | 3А |
| 4 | | Мөрәҗәгать итүче вәкиле | 4А |

Регламентка
3 нче кушымта

**Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А-4А | Гариза | Бердәм портал, Республика порталы, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 2. | 1А-4А | шәхесне таныклый торган документ (мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхсән кабул иткәндә Россия Федерациясе гражданы паспортын я шәхесне таныклый торган башка документны күрсәтү юлы белән яисә 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күп функцияле үзәкләрдә идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән башкарылырга мөмкин) | Бердәм портал, Республика порталы, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 3. | 4А | Мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ | «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 4. | 1А-4А | Җир кишәрлегенең урнашу схемасы | Бердәм портал, Республика порталы, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | комитет, Палата, КФҮ |
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар* | | | |
| 1. | 1А-4А | Җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең, арендаторларның җир кишәрлекләре ясауга ризалыгы (башлангыч җир кишәрлеге өченче затларга бирелгән очракта мәҗбүри ) | Бердәм портал, Республика порталы, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 2. | 1А-4А | Башлангыч җир кишәрлекләренең закладка алучыларның язма рәвештә ризалыгы (мондый җир кишәрлегенә милек хокукы залог белән йөкләнгән очракта мәҗбүри) | Бердәм портал, Республика порталы, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |

Регламентка
4 нче кушымта

**Хезмәт күрсәтүдән баш тарту һәм хезмәт күрсәтү өчен гаризаны һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен тулы нигезләр**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны |
|---|---|---|
| | | *Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр* |
| 1. | 1А-4А | Җир кишәрлеген урнаштыру схемасы формасы, форматы яки аны әзерләү таләпләренә туры килми |
| 2. | 1А-4А | Барлыкка килү схемасында каралган җир кишәрлегенең урнашу урыны җир кишәрлегенең гамәлдә булу срогы чыкмаган җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында элек кабул ителгән карар нигезендә төзелә торган җир кишәрлегенең урнашу урыны белән тулы яисә өлешчә туры килүе |
| 3. | 1А-4А | Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренә карата РФ Җир кодексының 11.9 статьясы таләпләрен бозып, җир кишәрлегенең урнашу схемасын эшләү. |
| 4. | 1А-4А | Территорияне планлаштыруның расланган проектына, җир төзелеше документациясенә, махсус сакланыла торган табигать территориясе турындагы нигезләмәгә җир кишәрлеге урнашу схемасының туры килмәве |
| 5. | 1А-4А | Җир кишәрлеген төзү, җир кишәрлегенең урнашу схемасында каралганча, расланган территорияне ызанлау проекты буенча территория чикләрендә урнашуы, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 6. | 1А-4А | Территориянең расланган ызанлау проекты нигезендә генә барлыкка килергә рөхсәт ителә торган җир кишәрлегенең урнашу схемасын эшләү |
| 7. | 1А-4А | Җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы хәбәрнамәсе; |
| 8. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны кире алу |
| | | *Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр* |
| 1. | 1А-4А | Регламентның 3 нче кушымтасында билгеләнгән документларны тапшырмау; |
| 2. | 1А-4А | Ведомствоара мәгълүмати бәйләнеш кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турында белешмәләр расланмау, мөрәҗәгать итүче исеменнән гариза (рәсми мөрәҗәгать) моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы; |
| 3. | 1А-4А | Документларны тиешле булмаган органга тапшыру; |
| 4. | 1А-4А | Дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр, килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлеген аңларга мөмкинлек бирми торган җитди зарарланулар булган документларны, үз көчен югалткан документларны тапшыру; |
| 5. | 1А-4А | Регламент нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүне алучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе; |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | 1А-4А | Гаризаның электрон формасында мәҗбүри юлларны корректлы тутырмау, электрон формада һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу; |
| 7. | 1А-4А | Гаризада һәм аңа кушып бирелгән документларда каршылыклы белешмәләр булу |
| 8. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документ текстында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерүләр һәм төзәтүләр булу |

5 нче кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** Зеленодольск шәһәре **БОЕРЫК**

**_______ _______** **№ _____ _____**

**Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслау турында**

Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслау өчен ____ № _______________ гаризасын (Мөрәҗәгать итүче: ____________________), һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны карап , __________________, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ боера:

1. Җир кишәрлегенең урнашу схемасы буенча___________________территория зонасында/________ рөхсәт ителгән файдалану төре ______ мәйданы, __________________җир категориясеннән , ____________________адресы буенча урнашкан, кадастр номерлары ______________ булган территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын расларга.

2. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ дәүләт күчемсез мөлкәт кадастрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен кадастр исәбенә алу органына кирәкле документларны тапшыруны тәэмин итәргә.

2.1. ____________________мөрәҗәгать итүчегә әлеге Боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген ясау эшләрен башкаруны аның урнашу схемасы нигезендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген файдалануда түбәндәге чикләүләрне билгеләргә (әгәр чикләүләр булса):______________

4. Мөрәҗәгать итүчегә әлеге күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашыру турындагы гариза белән ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә вәкаләт бирергә.

5. Әлеге карарның гамәлдә булу вакыты ике ел тәшкил итә.

______________________________________________ ____________________

(*карар кабул итүне гамәлгә ашыручы органның вәкаләтле заты вазыйфасы*) (*имза*) (*инициаллары*)

Электрон имза турында белешмәләр

6 нчы кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

| **РАСПОРЯЖЕНИЕ** | Зеленодольск шәһәре | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| **_____ ____ _______** | | **№ _____ _____** |

**Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслау турында**

Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслау өчен ____ № _______________ гаризасын (Мөрәҗәгать итүче: ____________________________________), һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны карап , __________________, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ боера:

1. Җир кишәрлегенең урнашу схемасы буенча___________________территория зонасында/_______ рөхсәт ителгән файдалану төре _____ мәйданы, __________________җир категориясеннән , ____________________адресы буенча урнашкан, кадастр номерлары ______________ булган территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын расларга.

2. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ дәүләт күчемсез мөлкәт кадастрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен кадастр исәбенә алу органына кирәкле документларны тапшыруны тәэмин итәргә.

2.1. ____________________мөрәҗәгать итүчегә әлеге Боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген ясау эшләрен башкаруны аның урнашу схемасы нигезендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген файдалануда түбәндәге чикләүләрне билгеләргә (әгәр чикләүләр булса):______________

4. Мөрәҗәгать итүчегә әлеге күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашыру турындагы гариза белән ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә вәкаләт бирергә.

5. Әлеге карарның гамәлдә булу вакыты ике ел тәшкил итә.

| _______________________ | _______________________ | _______________________ |
|---|---|---|
| (*карар кабул итүне гамәлгә ашыручы органның вәкаләтле заты вазыйфасы*) | (*имза*) | (*инициаллары*) |

Электрон имза турында белешмәләр

7 нче кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

*(гражданнар һәм ИП өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме,*

*(оешманың тулы атамасы*
*-юридик затлар өчен)*

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында

КАРАР

______________ № ____________

___ № _______________ гаризасын (Мөрәҗәгать итүче: ____________________________________), һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны карап , Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясы нигезендә территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслаудан түбәндәге нигездә кире кагылды:

______________________________________________________________________.

Баш тарту сәбәпләрен аңлату:

_____________________________.

Өстәмә хәбәр итәбез:___________________________________________________

______________________________________________ ____________________

(*карар кабул итүне гамәлгә ашыручы органның вәкаләтле заты вазыйфасы)*
)

(*имза*)

(*инициаллары*)

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

8 нче кушымта

Юридик затлар өчен

______________________________________
(җирле үзидарә органы атамасы)

______________________________________

______________________________________
(оешманың тулы исеме һәм оештыру-хокукый формасы)

______________________________________

______________________________________
(Җитәкченең яисә башка вәкаләтле затның ФИАт.и.
исеменнән
Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ:

______________________________________
(документ төре)

______________________________________
(сериясе, номеры)

______________________________________
(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)
Дәүләт теркәве турында юридик затның белешмәләре:

Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН)

______________________________________

______________________________________
Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН)

______________________________________
Урнашу урыны

______________________________________

______________________________________
Элемтә өчен мәгълүмат:

1 тел. номеры ______________________________

2 тел. номеры ______________________________

электрон почта ______________________________

Физик затлар һәм
индивидуаль эшкуарлар өчен

ФИАт.и.

______________________________________
Шәхесне таныклый торган документ:

______________________________________
(документ төре)

(сериясе, номеры)

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

ОРГНИП (индивидуаль эшкуарлар өчен)

Теркәлү адресы

Ышанычнамә буенча вәкил яки законлы вәкиле:

ФИАт.и.

Шәхесне таныклый торган документ:

(документ төре)

(сериясе, номеры)

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары:

Теркәлү адресы

Элемтә өчен мәгълүмат:

1 тел. номеры ______________________

2 тел. номеры ______________________

электрон почта ______________________

ГАРИЗА

Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раславыгызны сорыйм.

___________ кв. м мәйданлы җир кишәрлеге ,.___________________________ ур., ________йорт адресы буенча урнашкан

________________________________________________________________________.

(җир кишәрлегенең адресы булмаганда, җир кишәрлеге урнашу урынының башка тасвирламасы).

Җир кишәрлегенең кадастр номеры яки җир кишәрлекләренең кадастр номерлары __________________, ________________________, ________________________,

(болар җир кишәрлеге(җир кишәрлекләре) турында күчемсез милекнең дәүләт кадастрына мәгълүмат кертелгән җир кишәрлегеннән(җир кишәрлекләреннән) ясалган очракта (күрсәтелә)

______________________________________________________________________.
(чикләрендә җир кишәрлеге барлыкка килә торган яисә барлыкка килә торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре булган территория зонасы)

Җир кишәрлеге түбәндәгеләргә карый____________________________________.
(Җир категориясе күрсәтелә)

Җир кишәрлегеннән файдалануның күздә тотыла торган максаты:_____________________________________________________.
(җир кишәрлегеннән файдалану максаты, шул исәптән төзелеш белән бәйле булмаган максатлар да күрсәтелә)

| |
|---|
| Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен минем адреска түбәндәге юл белән тапшыруыгызны (җибәрүегезне) сорыйм: |
| ☐ Дәүләт хезмәтләре бердәм порталының шәхси кабинетына электрон рәвештә<br>☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы<br>☐ Хезмәт күрсәтүче органда<br>☐ КФҮкә |

Мөрәҗәгать
итүченең имзасы ________________________
(имзаның аңлатмасы)

Дата ____________________________________

9 нчы кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

Җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең территория кадастр планында урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

_____________________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

( мөрәҗәгать итүче- физик затның Ф. И. Ат.и., юридик затның исеме )

___________________ел, гариза №__

______________________________________________________________________

_________турында

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, түбәндәгеләргә таянып, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

1.

2.

Вазифаи зат (ФИАт.и.) ________________________________

(имза салуны гамәлгә ашыручы органның вазифаи заты имзасы)

Башкаручы (Ф.И.Ат.и)

___________________________________

(башкаручы белән элемтә өчен белешмәләр)

| |
|---|
| Электрон имза турында белешмәләр |